РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Мунайкинского
сельского поселения
Менделеевского муниципального
района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеев муниципаль районы
Монай авыл жирлеге Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2020 елның 14 августыннан

№179

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2019 елның 04 октябрендәге 144 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 6 июненнән 79 номерлы Монай авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2013 елның 6 июненнән 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:
- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы Карары проектын карап тикшерү буенча гавами тыңлаулар 2020 елның 17 сентябрендә 16 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Монай авыл җирлеге, Монай авылы, Төзүчеләр ур., 12 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге мәдәният йорты бинасының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карар проекты белән танышу чорында югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәләр: Татарстан Республикасы, Монай авыл җирлеге, Монай авылы, Ленин урамы, 54 нче йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Монай авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Монай авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.М.Кириллов

.

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы
Монай авыл җирлеге
Советының
2020 елның 15 августыннан
179 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Кириллов Руслан Михайлович - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Рәис урынбасары: Семенов Сергей Михайлович - йорт эчендәге газ җиһазлары хезмәте начальнигы;
3. Секретарь: Сазонова Лариса Тимерхановна – Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Әбүбәкеров Илдар Шәүкәт улы – Монай авыл җирлеге Советы Депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Әскәров Таһир Наил Улы – Монай авыл җирлеге Советы Депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы Инвестицион һәм инфраструктур үсеш идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.